КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 февраль г.Казань № 103

Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын үстерү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе территориясендә ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын камилләштерү турында» 2010 елның 28 декабрендәге 1632 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасы турында» 2011 ел, 21 ноябрь, 958 нче карары, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын үстерү турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә «112» телефон номеры буенча кичектергесез оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасы турында» 2010 ел, 22 март, 166 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә «112» телефон номеры буенча кичектергесез оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасы турында» 2010 ел, 22 март, 166 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 28 декабрь, 1082 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм үз көчен югалткан дип тану турында» 2012 ел, 22 март, 233 нче карарының 1 пунктындагы дүртенче, бишенче абзацлар;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм үз көчен югалткан дип тану турында» 2012 ел, 17 август, 712 нче карарының 1 пунктындагы ундүртенче – уналтынчы абзацлар.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин